**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**

**КАРАР**

**«06» апрель 2026 ел** **№ 30**

**Нурлат муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру турында Нигезләмәне раслау хакында» 2016 елның 18 апрелендәге 38 номерлы карары үз көчен югалткан дип тану турында**

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартндагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 28 декабрендәге 505-ФЗ номерлы Федераль закон, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексының 18 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Үз көчен югалткан дип танырга:

1.1. Нурлат муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру турында Нигезләмәне раслау хакында» 2016 елның 18 апрелендәге 38 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга

1.2. Нурлат муниципаль районы Советының «Цифрлы финанс активлары һәм цифрлы хокуклар турында белешмәләр бирү турында һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Советының керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакында аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 28 маендагы 65 номерлы карарының 2 пункты.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында

https://pravo.tatarstan.ru/ һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Советы Рәисе Д.А. Ишкинеев